КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 декабрь г.Казань № 1587

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының кайбер нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруны гамәлгә ашыруны оештыру муниципаль белем бирү оешмаларының матди-техник базасын ныгыту өлешендә балаларны карап тоту һәм карау, балаларны карап тоту өчен шартлар тудыруга (финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь, 976 нчы карары белән расланган Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруны гамәлгә ашыруны оештыру муниципаль белем бирү оешмаларының матди-техник

базасын ныгыту өлешендә балаларны карап тоту һәм карау, балаларны карап тоту өчен шартлар тудыруга (финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 8 пунктындагы өченче абзацы һәм 9 пунктындагы өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 4 февраль, 56 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 6 пунктындагы өченче абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин